КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 октябрь г.Казань № 959

«Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы, «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами -хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында, $13^1$ статьясындагы $3^1$ һәм $3^2$ өлешләрендә каралган чараларны финанслау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы
карары белән расланды

«Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның
хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә (алга таба – Фонд) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында, $13^1$ статьясындагы $3^1$ һәм $3^2$ өлешләрендә каралган чараларны финанслау максатларында Фонд мөлкәтенә Татарстан Республикасының мөлкәти кертеме рәвешендә (алга таба – Субсидия) бирелә.

3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында һәм (яки) Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә

4. Субсидия Фонд мөлкәтенә Татарстан Республикасының мөлкәти кертеме рәвешендә субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енә Фондның түбәндәге таләпләргә туры килү шарты белән бирелә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмау;

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, Фонд эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаска тиеш.

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

Фонд тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында, $13^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны финанслау турында яки чараларны финанслау максатка туры килмәү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1192 номерлы карары белән расланган Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, $13^1$ статьясындагы 2 өлеше белән каралган чараларны финанслау турында яки чараларны финанслау максатка туры килмәү турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба – Карар кабул итү кагыйдәләре) нигезендә чараларны финанслау турында карар кабул итү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Фондның Субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә Фонд ризалыгы.

5. Субсидия алу өчен Фонд Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә язылган һәм Фонд җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган Субсидия бирүгә заявка (алга таба – Заявка);

Фонд җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган, салым органы мәгълүматлары нигезендә Фондның салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турында мәгълүмат, Фондның үзгәртеп оештыру яки бетерү процессында булмавы турында, шулай ук Фондка карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы турында мәгълүмат бирелгән хат;

вәкаләтле затның вәкаләтен раслый торган документ (әгәр мондый зат бердәм башкарма орган булмаса).

6. Фонд үз инициативасы белән түбәндәге документларны күрсәтергә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсен;

Фондның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булу (булмау) турындагы мәгълүматларны.

7. Фонд әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык Заявканы теркәлгән документлары белән кабул итүне һәм кергән көнендә теркәүне гамәлгә ашыра.

9. Министрлык Фондтан Заявка һәм әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән документларны алган көннән өч эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә аларның комплектлыгын тикшерә һәм Субсидия бирү турында йә Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә Фондка Субсидия бирүдән баш тарту турында язма хәбәрнамә җибәрә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Фондның әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән документларны тапшырмавы йә әлеге документларны тулы күләмдә тапшырмавы;

Фондның салым органы мәгълүматлары нигезендә салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булуы;

Фондның үзгәртеп оештыру яки бетерү процессында булуы, яисә Фондка карата банкротлык процедурасы билгеләнүе, Фонд эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылуы.

11. Субсидия Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы буларак Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә бирелә.

12. Субсидия бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Фонд арасында Карар кабул итү кагыйдәләренең кушымтасында билгеләнгән килешүнең бертип формасы буенча төзелә торган Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны үтәү һәм Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү тора:

«Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами -хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә торак урыннар бирү буенча йөкләмәләр үтәлгән яисә акча түләнгән өлешле төзелештә катнашучылар саны.

14. Субсидия күчерү Министрлык тарафыннан Килешү нигезендә әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында каралган документларны тапшырган көннән биш эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә «Торак өлкәсендә идарә итүнең нәтиҗәлелеген үстерүгә һәм арттыруга булышлык күрсәтү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 225-ФЗ номерлы Федераль законның $2^1$ статьясы нигезендә торак төзелеше

өлкәсендә вәкаләтле банк булып торучы кредит оешмасында Фонд өчен ачылган счетка гамәлгә ашырыла.

15. Фонд Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Килешүдә билгеләнгән форма һәм сроклар буенча Фондның әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән Субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешүе турында хисап бирә.

16. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Фондның Субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерәләр үткәрә.

17. Тикшерү йомгаклары буенча Фонд тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән Субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозулар факты ачыкланган, шулай ук Фонд тарафыннан әлеге Тәртип һәм Килешү нигезендә тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар күрсәтелгән очракта. Субсидия яки аның бер өлеше кире кайтарылырга тиеш.

18. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән фактлар билгеләнгән көннән 30 календарь көн эчендә Фондка Субсидияне яки аның бер өлешен кире кайтару кирәклеге турында язма хәбәрнамә җибәрә, анда Субсидияне кире кайтару өчен нигез булып торган сәбәпләрне һәм акча күчерү өчен реквизитларны күрсәтә.

Фонд Субсидияне яки аның бер өлешен кире кайтару кирәклеге турында язма хәбәрнамә алган көннән 30 календарь көн эчендә Субсидия акчасын кире кайтарырга тиеш.

Фонд Субсидия акчасын иректе тәртиптә кире кайтарырга баш тартса, Субсидия акчасы Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

19. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Фондтан әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга юнәлдерүгә ихтыяҗны нигезли торган документларны алганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Килешүнең кушымтасында билгеләнгән хисап датасына Субсидиянең файдаланылмый калган өлешен әлеге максатларда файдалану турында карар кабул итә.